СОВЕТ БАВЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАУЛЫ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ СОВЕТЫ

---

РЕШЕНИЕ КАРАР

12.12.2024 Баулы шәһәре № 284

Баулы муниципаль район милкендәге,
хуҗалык алып бару хокукында йә оператив
идарә хокукында муниципаль мәдәният
оешмаларына беркетелгән мөлкәтне
арендага тапшыруны килештерү тәртибен
раслау турында

«Конкуренцияне яклау турында» 2006 елның 26 июлендәге 135-ФЗ номерлы Федераль законның 17.1 статьясындагы 3.5 өлеше, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2021 елның 9 сентябрендәге 1529 номерлы карары белән расланган, хуҗалык алып бару яисә дәүләт яки муниципаль мәдәният оешмаларына оператив идарә итү хокукында беркетелгән дәүләт һәм муниципаль мөлкәткә карата конкурслар яисә аукционнар үткәрмичә аренда шартнамәләре төзү Кагыйдәләренең 8 пункты нигезендә, Баулы муниципаль район Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Баулы муниципаль районы милкендәге, хуҗалык алып бару хокукында йә оператив идарә хокукында муниципаль мәдәният оешмаларына беркетелгән мөлкәтне арендага тапшыруны килештерү тәртибен расларга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат Рәсми порталында һәм Баулы муниципаль район сайтында «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрендә бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Баулы муниципаль район Советының икътисади үсеш, эшмәкәрлек, кече бизнес һәм торак-коммуналь хуҗалык сораулары буенча даими комиссиясенә йөкләтергә.

Баулы муниципаль районы Башлыгы,
район Советы рәисе И.И. Гозәеров

Баулы муниципаль район<br>Советының 2024 елның<br>12 декабрендәге 284 номерлы<br>карары белән<br>РАСЛАНГАН

Баулы муниципаль районы милкендәге хуҗалык алып бару хокукында йә оператив идарә итү хокукында муниципаль мәдәният оешмаларына беркетелгән мөлкәтне арендага тапшыруны килештерү
тәртибе

1. Әлеге тәртип Баулы муниципаль районы мәдәният оешмасы (алга таба – муниципаль мәдәният оешмасы) тарафыннан муниципаль мәдәният оешмасына хуҗалык алып бару йә оператив идарә итү хокукында беркетелгән Баулы муниципаль районы муниципаль мөлкәтен (алга таба – мөлкәт) конкурслар яисә аукционнар үткәрмичә генә арендага тапшыруны муниципаль мөлкәтне гамәлгә куючы һәм милекче белән килештерү процедурасын билгели.

2. «Конкуренцияне яклау турында» 2006 елның 26 июлендәге 135-ФЗ номерлы Федераль законның 17.1 статьясындагы 3.5 өлеше нигезендә, аренда шартнамәсе төзү кирәклеге турында гаризаны карау нәтиҗәләре буенча муниципаль мәдәният оешмасы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2021 елның 9 сентябрендәге 1529 номерлы «Дәүләт яисә муниципаль мәдәният оешмаларына хуҗалык алып бару йә оператив идарә итү хокукында беркетелгән дәүләт яисә муниципаль мөлкәткә карата аренда шартнамәләрен конкурслар яисә аукционнар үткәрмичә төзү кагыйдәләрен раслау турында» карары белән Баулы муниципаль районы мөлкәте милекчесе функцияләрен һәм вәкаләтләрен башкаручы (алга таба – мөлкәт милекчесе), гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен башкаручы (алга таба – гамәлгә куючы) Баулы муниципаль районы Башкарма комитетына мөрәҗәгать итүчегә мөлкәтне арендага бирүне килештерү турында мөрәҗәгать (алга таба – мөрәҗәгать) җибәрә.

3. Мөрәҗәгатьтә түбәндәге белешмәләр күрсәтелә:

1) фаразланган арендаторның исеме, аның урнашкан урыны турында белешмәләр, почта адресы һәм контакт телефоны номеры;

2) хуҗалык алып бару йә оператив идарә итү хокукында беркетелгән мөлкәт турында арендага тапшырырга тәкъдим ителә торган белешмәләр;

3) хуҗалык алып бару йә оператив идарә итү хокукында беркетелгән мөлкәтне арендага бирү аны нәтиҗәлерәк файдалануга ярдәм итәчәген нигезләү;

4) аренда шартнамәсен төзү тәкъдим ителә торган срок;

5) күздә тотыла торган арендаторны аңа мөлкәтне конкурс яисә аукцион уздырмыйча гына арендага бирү өчен сайлауны хокукый нигезләү:

а) арендаторның мөлкәткә ихтыяҗы, мөлкәттән файдалануның күздә тотыла торган максатлары;

б) муниципаль мәдәният оешмасына килүчеләргә һәм хезмәткәрләренә җәмәгать туклануы хезмәтләрен күрсәткәндә сату өчен тәкъдим ителә торган продукция һәм товарлар ассортименты турында мәгълүмат - җәмәгать туклануын оештыру өчен;

в) сувенир, нәшрият һәм аудиовизуаль продукция ассортименты турында мәгълүмат – ваклап сату белән шөгыльләнүче юридик затлар һәм индивидуаль эшмәкәрләр өчен.

4. Мөрәҗәгатькә түбәндәге документлар кушып бирелә:

1) мөлкәтне арендалау шартнамәсе проекты;

2) аренда түләвенең базар бәясен бәяләү турында бәяләү эшчәнлеге турында Россия Федерациясе законнары нигезендә әзерләнгән хисап (тапшыру датасына 90 көннән артмаган вакыт белән);

3) сувенир, нәшрият һәм аудиовизуаль продукцияне ваклап сатуны гамәлгә ашыручы күздә тотылган арендаторның (җәмәгать туклануы оешмасының, юридик затның яисә шәхси эшмәкәрнең) заявкасы күчермәсе;

4) шәхесне таныклаучы документның күчермәсе һәм шәхси эшмәкәрнең Бердәм дәүләт реестрыннан өземтә (искелек срогы белән) 30 көннән дә артык түгел) – шәхси эшмәкәрләр өчен;

5) юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан өземтә (вакыты 30 көннән артмаган) – юридик затлар өчен.

5. Муниципаль мәдәният оешмасына мөлкәтнең бер төрен (төрләрен) арендалауга карата ике һәм аннан күбрәк мөрәҗәгать итүчедән гаризалар кергән очракта, мөрәҗәгать гаризалар кергән көннән чыгып чират тәртибендә җибәрелә.

6. Муниципаль мөлкәт милекчесе һәм гамәлгә куючы мөрәҗәгатьне һәм аңа кушып бирелгән барлык документларны алар кергән көннән алып 20 эш көне эчендә карыйлар һәм түбәндәге карарларның берсен кабул итәләр:

1) мөлкәтне арендага тапшыруны килештерергә;

2) мөлкәтне арендага бирүне килештерүдән баш тартырга.

7. Мөлкәтне арендага бирүне килештерүдән баш тарту өчен нигезләр булып:

1) мөлкәтне арендага бирү муниципаль мәдәният оешмасы эшчәнлеген нәтиҗәлерәк оештыруга булышлык итмәячәк;

2) мөлкәтне арендага бирү максатлары муниципаль мәдәният оешмасының уставында каралган эшчәнлек төрләренә туры килми;

3) мөлкәтне арендага бирү элек чират тәртибендә кергән гаризага карата мөрәҗәгатьне карау нәтиҗәләре буенча килештерелгән.

8. Кабул ителгән карар мөлкәт милекчесе тарафыннан Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты карары рәвешендә һәм гамәлгә куючы тарафыннан муниципаль хокукый акт рәвешендә рәсмиләштерелә һәм ул кабул ителгән көннән алып 5 көн эчендә муниципаль мәдәният оешмасына җибәрелә.

9. Милекне арендага бирүне килештерүдән баш тарту турындагы карарда баш тарту сәбәпләрен нигезләү булырга тиеш.

Мөлкәтне арендага бирүне килештерүдән баш тарту турында карар кабул ителгәндә, мөрәҗәгать һәм аңа беркетелгән документлар, муниципаль мәдәният оешмасына мондый карар кабул ителгән көннән алып 5 көн эчендә кире кайтарыла.

10. Мөлкәтне арендага бирүне килештерү турында кабул ителгән карар мәдәният муниципаль оешмасы тарафыннан мөлкәтне конкурслар яисә аукционнар үткәрмичә генә арендалау шартнамәсен төзү өчен нигез булып тора.

11. Муниципаль мәдәният оешмасы аренда шартнамәсе төзелгән көннән алып 10 көн эчендә мөлкәтне гамәлгә куючыга һәм милекчегә аренда шартнамәсе төзелү турында (арендага бирелгән мөлкәт исемлеге һәм аны арендага бирү срогы кушымтасы белән) язма рәвештә хәбәр итә.